ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

д. им. М. Вахитова

21.11.2015 № 1

Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советының «2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатларында "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә 2016 елга гавами тыңлаулар уздыру юлы белән Вахитов авыл җирлеге бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советының 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең бюджеты турында карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 03 декабрендә 14.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. Үткәрү урыны - М.Вахитов ис. авыл,Үзәк ур., 24 йорт, авыл мәдәният йортында

2.4. Фикер алыша торган мәсьәлә буенча ачык тыңлауларда катнашу өчен, чыгыш ясау хокукы белән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә мөмкин булган адрес - М.Вахитов ис. авыл, Үзәк ур. 28 йорт, авыл җирлеге башлыгы Җәләлетдинов А.Ш. (эш көннәрендә - “8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен чыгыш хокукы белән гаризалар бирү срогы - 2015 елның 28 ноябренә кадәр (тел 30-1-48).

3. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советының гамәлдәге законнар һәм әлеге карарда билгеләнгән сроклар нигезендә "Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге бюджеты турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советына халык алдында тыңлауларның беркетмәсен, халык алдында тыңлауларның тәкъдимнәрен, халык алдында тыңлауларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге бюджетының 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) бюджет проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советының "Югары Ослан муниципаль районының 2016 елга Вахит авыл җирлеге бюджеты турында" карар проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Вахитов авыл җирлеге башлыгы А.Ш. Җәләлетдинов